ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 сентябрь 2026 ел № 9902

Башкарма комитетның «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 2 июнендәге 4666 номерлы Карары үз көчен югалтуны тану хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21, 5.22, 5.23 пунктлары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комите Карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2023 елның 7 июнендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 2 июнендәге 4666 номерлы;

2) 2024 елның 26 июнендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Башкарма комитетның 2023 елның 2 июнендәге 4666 номерлы Карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 21 июнендәге 3985 номерлы;

3) 2024 елның 11 сентябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Башкарма комитетның 2023 елның 2 июнендәге 4666 номерлы Карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 6 сентябрендәге 5753 номерлы.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында

(https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары М.Ә. Фәттаховка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов